РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» апрель 2023 ел г. Альметьевск № 865

**Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 10 декабрендәге 2053 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясы нигезендә, хокукый мониторинг кысаларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 10 декабрендәге 2053 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 25 мартындагы 509 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

карарага 1 нче кушымтаның 1 бүлегендәге 1.2 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов

Зак. № 305-2000